РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«24» июнь 2019 ел г. Альметьевск № 55

Татарстан Республикасы Әлмәт
муниципаль районы башлыгының
2016 ел 6 маендагы № 34
«Татарстан Республикасы Әлмәт
муниципаль районының гадәттән
тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү
буенча территориаль ярдәмче
системасының җирле звеносы турында»гы
карарына үзгәрешләр кертү турында

Кадрлар үзгәреше белән бәйле рәвештә

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы башлыгының 2016 ел 6 маендагы № 34 «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасының җирле звеносы турында»гы карарына (Әлмәт муниципаль районы башлыгының 2017 ел 8 февралендәге № 25, 2017 ел 26 маендагы № 78, 2017 ел 26 сентябрендәге № 163, 2018 ел 30 гыйнварендәге № 06, 2018 ел 12 декабрендәге № 176 карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 нче кушымтада:

комиссия әгъзасы составына кертергә:

Гомәрова Р.К. - «Таттелеком» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры урынбасары - Әлмәт зонасы электр элемтәсе бүлеге җитәкчесе (килешү буенча);

Хөсәенова Р.И. - Татарстан Республикасы буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең күзәтчелек һәм профилактик эшчәнлеге идарәсенең Әлмәт муниципаль районы буенча бүлек башлыгы вазифаларын вакытлыча башкаручы (килешү буенча);

Кюрегян Р.Л. - «Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләренең ведомстводан тыш сак идарәсе» Федераль дәүләт учреждениесенең Әлмәт районы буенча ведомстводан тыш сак бүлеге башлыгы вазифаларын вакытлыча башкаручы (килешү буенча);

комиссия әгъзалыгыннан чыгарырга: Андреева Е.В., Нәбиева Р.М., Шәяхмәтова И.Р.

2. Район башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район башкарма комитеты җитәкчесе М.Н. Гирфановка йөкләргә.

Муниципаль район башлыгы
вазифаларын башкаручы — А.А.Зимин